# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлегенең Янурыс авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 22 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең Янурыс авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Янурыс авылы торак пунктында I төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан, шул исәптән катнашучы контрактчылардан (махсус хәрби операция барышында) һәм аларның гаилә әгъзаларенән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Янурусово торак пунктындагы зират территориясендә төзелеш материаллары сатып алу һәм койма урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);
2) Янурыс авылы мәдәният йорты территориясен төзекләндерү. Төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу, брусчатка салу, куаклар һәм агачлар кисү;
3) Янурыс, Иске Әхмәт торак пунктларында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (светодиодлы лампаларны сатып алу һәм урнаштыру);
4) Янурыс авылында бәйрәмнәр һәм спорт чаралары үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
5) тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу)
6) Ленин урамындагы тыкрыкта таш жэю

3. Әлеге карарны Янурыс авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А. Ә.Мөхәммәдиева